# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **17.11.2023 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Микулино авыл җирлеге
Благодатный бистәсендә гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештырунын гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 17 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, көндезге формада белем алучы студентлар, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына карата, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- Благодатный бистәсендә, Бакча һәм Урман урамнарында вак таш сатып алу һәм юл чокырларын эшләү;
- юлларны кардан чистарту.

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 119 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 119 кеше “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районы Микулино авыл жирлеге Благодатный торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм

катнашучылары, көндезге формада белем алучы студентлар, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына карата, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- Благодатный бистәсендә, Бакча һәм Урман урамнарында вак таш сатып алу һәм юл чокырларын эшләү;
- юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Микулино авыл җирлегенең Благодатный торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан: Микулино авылы, Совет урамы, 74, Благодатный бистәсе, Кояшлы ур., 7 мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Элеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл жирлеге башлыгына жибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Микулино авыл җирлеге Башлыгы: И.А.Такиулин